# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә
Чәкән торак пунктында үзара салым кертү
турында

**30 октябрь 2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентларыннан, гайлә әгъзасы махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаиләләрдән кала һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Чәкән торак пункты территориясе төзекләндерүне оештыру (ягулык-майлау материаллары сатып алу, карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен тракторчыга түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Чәкән торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Кече авыл бәйрәмнәрен» үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен хезмәт күрсәтү);
- Чәкән авылы зиратына керү юлларына вак таш җәю, юлны ныгыту өчен торба (яңгыр канализациясе) салу;

3. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Җыелышта рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районының
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Г.И. Әскәрова